**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 сентябрь № 678

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү буенча комиссия составында:

комиссия составыннан Х.Ә.Баһмановны чыгарырга;

комиссия составына Дамир Һарун улы Сафиуллинны – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын кертергә;

әлеге карар белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 июнь, 421 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\678.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 сентябрь, 678 нче карары белән расланды

# Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс (алга таба – Конкурс) ел саен, хисап елында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын һәм бюджет өлкәсе учреждениеләрен, муниципаль берәмлекләрне, Татарстан Республикасы предприятиеләрен һәм оешмаларын бүләкләү максатларында, Казан шәһәрендә энергия ресурсларын саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләре буенча халыкара симпозиум һәм халыкара махсуслаштырылган күргәзмә үткәрү кысаларында үткәрелә.

1.2. Конкурс «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең мәгълүмати-аналитик ярдәме белән Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан үткәрелә.

1.3. Конкурс материалларын кабул итү ел саен 20 гыйнвардан алып һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым боерыгы белән билгеләнә торган энергия ресурсларын саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләре буенча халыкара симпозиум һәм халыкара махсуслаштырылган күргәзмәне үткәрә башлаган көнгә кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

1.4. Конкурс үткәрү турындагы хәбәр Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сайтында (http://mpt.tatarstan.ru) «Республика конкурслары» бүлегендә конкурс материалларын кабул итү тәмамланган көнгә кадәр календарь көннәрендә исәпләнә торган 45 көн эчендә урнаштырыла.

1.5. Конкурс үткәрү турындагы хәбәр үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

Конкурсның предметы;

конкурс материалларын кабул итү башланган һәм тәмамланган көн;

конкурс материалларын кертү вакыты һәм урыны;

конкурс материалларын кабул итүне гамәлгә ашыручы зат белән элемтә өчен телефон номеры;

конкурс материаллары исемлеге.

## 2. Конкурс номинацияләре

2.1. Конкурс 12 номинация буенча үткәрелә:

«Муниципаль берәмлекләр» номинациясе;

«Социаль тармак» [1] номинациясе;
«Электр энергетикасы» номинациясе;
«Химия һәм нефть химиясе» номинациясе;
«Оборона-сәнәгать комплексы» номинациясе;
«Машина төзелеше» номинациясе;
«Ягулык тармагы» номинациясе;
«Җиңел сәнәгать, азык-төлек, агач эшкәртү сәнәгате» номинациясе;
«Торак-коммуналь хуҗалык» номинациясе;
«Транспорт һәм элемтә» номинациясе;
«Агросәнәгать комплексы» номинациясе;
«Кече һәм урта бизнес» номинациясе.

2.2. Конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле призлар тапшырыла.

2.3. Конкурста катнашучыларны тиешле номинация буенча бәяләү критерийлары әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

## 3. Конкурска материалларны кертү тәртибе һәм аларны формалаштыру

3.1. Конкурс материаллары үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

кандидат оешманың электрон адресын мәҗбүри күрсәтеп, кандидат оешма җитәкчесе яки аның вәкаләтле урынбасары тарафыннан имзаланган бергә теркәп җибәрелә торган хат;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программасы (ярдәмче программасы) чараларын гамәлгә ашыру турында хисап;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан күрсәткечләрнең мәгънәләренә ирешү турында хисап.

Конкурста катнашучының ихтыяры буенча конкурс материалларына өстәмә рәвештә энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программасын (яки программаның аерым чараларын) гамәлгә ашыру турында фото-, видео- һәм презентация материаллары кертелә ала.

3.2. Бергә теркәп җибәрелә торган хат Конкурста катнашучы кандидат оешманың бланкында формалаштырыла һәм 3.1 нче пунктта күрсәтелгән материаллар белән, аларның күләмен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 4 йорт (электрон почта адресы: mpt@tatar.ru).

3.3. 3.1 нче пунктта күрсәтелгән материаллар Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан алар министрлыкка кертелгән көнне теркәлә.

3.4. Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программасын (яки программаның аерым чараларын) гамәлгә ашыру турында фото-, видео- һәм презентация материаллары Конкурста катнашучының казанышларын чагылдырырга

---

[1] Конкурсны үткәрү кысаларында «Социаль тармак»ка мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт кебек тармаклардагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре карый

һәм 10 – 15 фотографиядән, биш слайдтан яки күп дигәндә 30 секундлык бер видеороликтан артык булмаган күләмдә кертелергә тиеш.

3.5. Конкурс материаллары кәгазьдә яки электрон мәгълүмат саклау җайланмаларында, шул исәптән электрон документлар әйләнеше белән.

3.6. Конкурс материаллары Конкурста катнашучыларга кире кайтарылмый.

3.7. Кертелгән документларның әлеге Нигезләмәдәге 3 бүлек таләпләренә туры килмәгәне ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы конкурс материалларын теркәгән көннән бер көн эчендә кандидат оешманың бергә теркәп җибәрелә торган хатта күрсәтелгән электрон адресы буенча кертелгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә эшләп бетерү кирәклеге турында кандидатка хәбәр итә.

## 4. Конкурс комиссиясе. Конкурска йомгаклар ясау, җиңүчеләрне бүләкләү

4.1. Конкурсны үткәрү өчен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы конкурс комиссиясе төзи. Конкурс комиссиясе әгъзаларының саны биш кешедән ким булмаска тиеш. Конкурс комиссиясе, әгәр аның утырышында комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 50 проценты катнашса, карарлар кабул итәргә хокуклы, һәм конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тавышы саныннан күпчелек тавышлар нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч санала. Конкурс комиссиясе үзенең эшчәнлегенә бәйсез экспертларны җәлеп итәргә хокуклы.

4.2. Түбәндәге физик затлар конкурс комиссиясе әгъзасы, бәйсез эксперт була алмый:

Конкурста катнашучылар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә булган;

суд карары белән юридик хокукка сәләтсез яки юридик хокукы чикләнгән дип танылган.

Конкурс комиссиясе составында әлеге затларның булуы ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аларны конкурс нәтиҗәләрендә шәхси мәнфәгатьләре булмаган башка физик затларга кичектергесез алыштырырга тиеш.

4.3. Конкурс комиссиясе түбәндәге вазыйфаларны башкара:

Конкурска кертелгән материалларны карап тикшерә;

Конкурска йомгаклар ясый.

4.4. Конкурс материалларын карап тикшерү агымдагы елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым боерыгы белән билгеләнә торган энергия ресурсларын саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләре буенча халыкара симпозиум һәм халыкара махсуслаштырылган күргәзмәне үткәрә башлаган көнгә кадәр 25 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

4.5. Конкурс материалларын бәяләү түбәндәге критерийлар буенча үткәрелә:

кертелгән конкурс материалларының әлеге Нигезләмәдәге 3 бүлеккә туры килүе;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә Конкурсның һәр номинациясе өчен билгеләнгән энергия ресурсларын саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы максатчан күрсәткечләргә ирешү.

4.6. Конкурска тәкъдим ителгән материалларны конкурс комиссиясе карап тикшерү нәтиҗәләре буенча һәр номинациядә җиңүчеләр билгеләнә, ләкин һәр номинация буенча күп дигәндә ике җиңүче, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең түбәндәге өч төркеменнән һәрберсендә бер генә җиңүче билгеләнә торган «Муниципаль берәмлекләр» номинациясеннән тыш:

үзәге республика карамагындагы шәһәр булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары;

шәһәр һәм авыл халкы булган муниципаль районнар;

бары тик авыл халкы булган муниципаль районнар.

Тиешле номинация буенча бер генә катнашучы гариза биргән булса, Конкурс җиңүчесе билгеләнми.

4.7. Конкурска йомгаклар ясау буенча конкурс комиссиясе утырышы агымдагы елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым боерыгы белән билгеләнә торган энергия ресурсларын саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләре буенча халыкара симпозиум һәм халыкара махсуслаштырылган күргәзмәне үткәрә башлаган көнгә кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча үткәрелә.

4.8. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, һәм ул конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс комиссиясе утырышын үткәргән көнне раслана.

Конкурс комиссиясе карарының беркетмәсе аны раслаган көнне Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сайтында (http://mpt.tatarstan.ru) «Республика конкурслары» бүлегендә урнаштырыла.

4.9. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру йомгакларын ясау буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында үткәрелә.

## 5. Конкурсны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

5.1. Конкурста җиңүчеләрне акчалата бүләкләүне финанслау күләмнәре һәм чыганаклары ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карары белән билгеләнә.

_______________________________

Энергия саклау һәм энергетика
нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә
иң яхшы казанышларга конкурс
үткәрү турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары

| Т/с | Номинация исеме | Бәяләү критерийлары (энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре) |
|---|---|---|
| 1. | «Муниципаль берәмлекләр» | биләгән мәйданның 1 кв.метрына (яки 1 кешегә) җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне тәэмин итүгә энергетика ресурслары һәм суның чагыштырма тотылуы;<br>файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәпләү җайланмалары һәм көйләү узеллары белән җиһазландырылган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр өлеше (процентларда);<br>энергия саклау буенча муниципаль программаның (ярдәмче программаның) башка максатчан күрсәткечләре |
| 2. | «Социаль тармак» | биләгән мәйданның 1 кв.метрына (яки 1 кешегә) дәүләт хакимияте органнарын һәм дәүләт учреждениеләрен тәэмин итүгә энергетика ресурслары һәм суның чагыштырма тотылуы;<br>файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәпләү җайланмалары һәм көйләү узеллары белән җиһазландырылган дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт учреждениеләре өлеше (процентларда);<br>энергия саклау буенча тармак программаның (ярдәмче программаның) башка максатчан күрсәткечләре |
| 3. | «Электр энергетикасы» | электр энергиясен эшләп чыгаруга шартлы ягулыкның чагыштырма тотылуы (г/кВт·сәг.);<br>җылылык энергиясен эшләп чыгаруга шартлы ягулыкның чагыштырма тотылуы (кг/Гкал);<br>энергия саклау буенча җитештерү программасының (ярдәмче программаның) башка максатчан күрсәткечләре |
| 4. | «Химия һәм нефть химиясе» | продукция җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтүнең энергия сыйдырышлылыгы (ш.я.т./млн.сум, чагыштырма бәяләрдә);<br>ягулык-энергетика ресурсларына һәм суга |
| 5. | «Оборона-сәнәгать комплексы» | |

| Т/с | Номинация исеме | Бәяләү критерийлары (энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре) |
|---|---|---|
| | | чыгымнарның гомуми күләменә карата энергетика ресурсларын һәм суны экономияләү чагыштырмасы (кыйммәти чагылышта) (млн.сум/млн.сум);<br>энергия саклау буенча җитештерү программасының (ярдәмче программаның) башка максатчан күрсәткечләре |
| 6. | «Машина төзелеше» | |
| 7. | «Ягулык тармагы» | |
| 8. | «Җиңел сәнәгать, азык-төлек, агач эшкәртү сәнәгате» | |
| 9. | «Агросәнәгать комплексы» | |
| 10. | «Торак-коммуналь хуҗалык» | җылылык энергиясен таратуга шартлы ягулыкның чагыштырма тотылуы (кг.ш.я./Гкал);<br>җибәрелгән җылылык энергиясенең гомуми күләмендә аны җибәргәндә югалтылган җылылык энергиясе өлеше;<br>энергия саклау буенча җитештерү программасының (ярдәмче программаның) башка максатчан күрсәткечләре |
| 11. | «Транспорт һәм элемтә» | продукция җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтүнең энергия сыйдырышлылыгы (ш.я.т./млн.сум, чагыштырма бәяләрдә);<br>ягулык-энергетика ресурсларына һәм суга чыгымнарның гомуми күләменә карата энергетика ресурсларын һәм суны экономияләү чагыштырмасы (кыйммәти чагылышта) (млн.сум/млн.сум);<br>энергия саклау программасының (ярдәмче программасының) башка максатчан күрсәткечләре |
| 12. | «Кече һәм урта бизнес» | |

_______________________

Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

20__ елның 1 гыйнварына
энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү программасы (ярдәмче программасы)
чараларын гамәлгә ашыру турында хисап

Оешма исеме: ______________________
Энергия саклау программасы (ярдәмче программасы) исеме: ______________________
Форманы тутыру өчен җаваплы зат
Ф.И.Ат.ис.: ______________________
Вазыйфасы: ______________________
Тел.: ____________________ Факс: ______________________ Электрон почта: _________________________

| Т/с | Чаралар исеме | Үтәү күләмнәре | | Ягулык-энергетика ресурсларын (ресурсларның төрләре буенча) һәм суны экономияләү | | | | | | | | Финанс чыгымнар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күләме | мәгънәсе | ресурс төре | табигый чагылышта | | | | кыйммәти чагылышта, мең сум | | | чыганагы | күләме, мең сум | | |
| | | | | | күләме | | | үлчәү берәмлеге | план | факт | % | | план | факт | % |
| | | | | | план | факт | % | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат) ____________________________________________ / ________________
(Ф.И.Ат.ис.) (имза)

Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

20__ елның 1 гыйнварына
энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә максатчан күрсәткечләрнең мәгънәләренә ирешү турында хисап

Оешма исеме: ______________________________________________

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткечләр мәгънәләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | база ел | | | хисап елы | | |
| | | | план | факт | % | план | факт | % |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат) ______________________________________________ / ______________
(Ф.И.Ат.ис.) (имза)